# ЯШЬЛЕГЕМ ТУГАЕ

*ЗИННУР ГЫЙБАДУЛЛИН музыкасы*
*ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН сүзләре*

Ничәнче мәртәбә
Нурланып яз килде,
Тургайлар канатын кагынды,
Күзләрең сагышлы,
Дип әйтте бер тургай,
Нишлим соң, тургаем, сагындым

Ничәнче мәртәбә
Тургайлар килделәр.
Тугайлар яшәрде, ямьләнде
Өздереп сайрады,
Сайрады бер тургай,
Читендер сагыну хәлләре

Өздереп сайрама,
Хәлемне сорама —
Ул үзе аңлар бер, тургаем.
Минем күк сагынып,
Кайтыр ул, тургаем:
Онытмас яшьлеге тугаен